| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.03.2021 № 169

2020 елның 13 ноябрендә кабул ителгән 944 номерлы муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларының яңа редакциясен раслау турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 13.11.2020 ел, №944 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль учреждениесенең муниципаль хезмәт күрсәтүләренең түбәндәге административ регламентларына үзгәрешләр кертергә:

- Муниципаль милек реестрыннан өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

- Муниципаль милектә булган һәм арендага бирү өчен билгеләнгән күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

- Муниципаль казнага кергән мөлкәтне арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

- Муниципаль милек реестрына керүче муниципаль милекне арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

- Муниципаль берәмлек мөлкәтен сатулар үткәрмичә генә түләүсез файдалануга тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

- Мондый шартнамә төзү хокукына аукцион нәтиҗәләре буенча муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану шартнамәсен төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

- Гамәлдәге муниципаль мөлкәтне арендалау Килешүен өзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

- Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына муниципаль милекне тапшыру һәм (яки) файдалануга тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты.

2.14 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алу максатларында инвалидларны социаль яклау тәэмин ителә: